ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**14.08.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1654**

24 нче бер мандатлы сайлау округы буенча өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы депутатын өстәмә сайлау буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Зеленодольск шәһәрендә махсус урыннар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67 номерлы Федераль законның 54 статьясын, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 пунктын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 24 нче бер мандатлы сайлау округы буенча өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы депутатын өстәмә сайлау буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Зеленодольск шәһәрендә махсус урыннар исемлеген кушымтада бирелгәнчә расларга.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Житәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 14 августындагы
1654 номерлы карарына
кушымта

24 нче бер мандатлы сайлау округы буенча өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы депутатын өстәмә сайлау буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Зеленодольск шәһәрендә махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Агитация басма материалларын элү өчен махсус урын урнашкан адрес буенча сайлау участогы үзәге | Адресы, элү урыны исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), стенд (бина стенасында, фойеда белдерүләр тактасы һ.б.) |
|---|---|---|
| 1531 | «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе, Зеленодольск шәһәре, Комаров урамы, 22а йорты. | мәгълүмат стенды |

Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыруның өстәмә урыннары - Зеленодольск шәһәренең сайлау участогы чикләрендә урнашкан күп фатирлы йортларда мәгълүмати щитлар.